Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы
Кощаково авыл җирлеге Советының утыз җиденче утырышы

Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы
Кощаково авыл җирлеге Советы
КАРАРЫ

04 октябрь, 2024 ел № 121

Питрәч муниципаль районының Кощаково авыл җирлеге торак пунктлары территориясе өлешендә гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча җыеннар билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1 һәм 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Питрәч муниципаль районы Кощаково авыл җирлеге уставының 23 статьясы, Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районының Кощаково авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын әзерләү һәм уздыру тәртибе турында нигезләмә, Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районының 2019 елның 08 ноябрендәге 62 номерлы (2021 елның 25 декабрендәге 37 номерлы карары белән кертелгән үзгәрешләр белән) Кощаково авыл җирлеге Советы карары нигезендә **Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Кощаково авыл җирлеге Советы карар кабул итте:**

1. Питрәч муниципаль районы Кощаково авыл җирлегендә түбәндәге торак пунктларда үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыеннарын билгеләргә:

1.1. Кощаково авылында.

- 2024 елның 19 октябрендә 10.00 сәгатьтә Аяз урамы буенча теркәлгән кешеләрнең гражданнар җыенын Аяз урамы тыкрыгында үткәрергә.

Гражданнар җыенына чыгарыла торган сорауны расларга:

«Сез 2025 елда Кощаково авыл җирлеге Кощаково авылының Аяз урамында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган һәр кешедән, махсус хәрби операциядә катнашучылар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан тыш 5000 сум күләмендә үзара салым кертү һәм җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару өчен куллану белән килешәсезме?:

- торак пункт чикләрендә (Аяз ур.) гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту

«РИЗА» «КАРШЫ».

1.2. Званка авылында.

- 2024 елның 19 октябрендә 11.00 сәгатьтә Урман һәм Ташлы урамнары буенча теркәлгән кешеләрнең гражданнар җыенын Урман һәм Ташлы урамнары тыкрыгында үткәрергә.

Гражданнар җыенына чыгарыла торган сорауны расларга:

«Сез 2025 елда Кощаково авыл җирлеге Званка авылы Урман һәм Ташлы урамнарында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган һәр кешедән, махсус хәрби операциядә катнашучылар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан тыш 2000 сум күләмендә үзара салым кертү һәм җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару өчен куллану белән килешәсезме?:

- торак пункт чикләрендә (Урман һәм Ташлы ур.) гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту

«РИЗА» «КАРШЫ».

2. Әлеге карарны «Вперёд» («Алга») газетасында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматның рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru), Питрәч муниципаль районы рәсми сайтында (www.pestreci.tatarstan.ru) һәм Кощаково авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

Кощаково авыл җирлеге башлыгы З.Н. Саттарова